РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендә кабул ителгән 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 321-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман районы прокуратурасының 2009 елның 16 декабрендәге 02-07-01/19 номерлы протесты, Илексаз авыл җирлеге Уставына карата Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советының «физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1.Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»

2) 2.1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. хуҗалык төзелешләре яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан;».

2.2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Илексаз авыл җирлеге
Советы Рәисе Ф.М. Гыйльфанов